КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 февраль г.Казань № 168

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 938 нче карары белән расланган Торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 938 нче карары белән расланган Торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә, 8.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«8.2. Төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) индикатив күрсәткечләре:

1) квартал саен хисап бирү бурычы булган торак-төзелеш кооперативларының гомуми саныннан күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында торак-төзелеш кооперативларының квартал саен тапшырыла торган хисап тотуларының өлешен законнарда билгеләнгән срокларда арттыру (үстерү), процент;

2) нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган тикшерүләр өлеше (2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булуы туктатып торылган аерым муниципаль берәмлекләрдә торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле төбәк дәүләт контроленә (күзәтчелегенә) карата), процент;

3) административ җәзаларның гомуми күләмендә кисәтүләр өлеше (2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булуы туктатып торылган аерым муниципаль берәмлекләрдә торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле төбәк дәүләт контроленә (күзәтчелегенә) карата), процент;

4) хисап чорында планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

5) хисап чорында контрольдә тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларында расланган параметрларга туры килүен яки контрольдә тотылучы объектның мондый параметрлардан читкә китүен ачыклау нигезендә планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

6) хисап чорында хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

7) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларының һәр төре буенча хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

8) хисап чорында үзара дистанцион хезмәттәшлек итү чараларыннан файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

9) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

10) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләр саны;

11) хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

12) хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

13) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

14) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

15) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм прокуратура органнары тарафыннан килештерелмәгән гаризалар саны;

16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектларның гомуми саны;

17) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

18) хисап чорында исәпкә алынган һәм аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы затлар саны;

19) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

20) хисап чорында контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) орган тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләр саны;

21) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән, карап тикшерү йомгаклары буенча контрольдә тотучы органның карарын тулысынча йә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органнарның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны;

22) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

23) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән, белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;

24) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.».

2. Бу карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин